УДК 930.2

# АЙДАР ХӘЛИМНЕҢ «ТАЛ БАЛАСЫ ТАЛХАВЕТДИН» ӘСӘРЕНДӘ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

**Г. М. Галимуллина**

galimullina.96@mail.ru

*Набережночелнинский государственный педагогический университет*

***Аннотация.*** *В статье производится краткий исторический очерк жизни и творчества известного татарского поэта, драматурга и публициста. Рассматривается нравственно-философский пласт его произведения "Сын ивы Талхаветдин". А также анализируется идейно-тематическое содержание рассказа.*

***Ключевые слова:*** *нравственно-философский пласт, идея, национальная концепция, символ*

Татар әдәбиятында заман шаукымына иярмәгән, кыйбласына тугрылык саклаган, әсәрләреннән зыялылык өртелеп торган әдипләр төркеме бар. Халык язмышы, милләт язмышын иң югары кыйммәт дип таныган мондый әдипләр арасында Айдар Хәлим (Борис Нәҗметдин улы Хәлимов) лаеклы урын алып тора.

Айдар Хәлим 1942 елның 1 нче гыйнварында Башкортстан Республикасының Миякә районы Бәләкәй (Кече) Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туа. Әтисе Бөек Ватан сугышының соңгы айларында һәлак булганлыктан, әдип бала чактан ук ярым ятим хәлдә, ачлы-туклы тормышның бөтен авырлыкларын күреп һәм үз җилкәсендә татып үсә. А.Хәлим тормышны төрле яктан күргән, төрле өлкәләрдә эшчәнлек күрсәткән тәҗрибәле кеше күзлегеннән бәяли. 1968 нче елларда Айдар Хәлим Түбән Кама шәһәрендә нефть химиясе комбинаты төзелешенең техник хәбәрдарлык бюросында инженер, радиожурналист, балта остасы булып эшли. Азатлыкка омтылу, каршылыкларны җиңеп чыгу, кыйбласына тугрылык саклау кебек сыйфатлары шушы елларда ачык чагыла башлый. Ул, Түбән Камада яшь әдипләрнең "Кама таңнары" исемле әдәби берләшмәсен оештыра һәм аны берничә ел буе җитәкли. Монда ул шулай ук татарның беренче мәдәни оешмалары, шул исәптән, атаклы "Җидегән чишмә" мәдәни-агарту берләшмәсенә, татар театрына нигез салуда турыдан-туры катнаша. Шушы елларда соңыннан татар, рус, башкорт телләрендә басылып, барча милләт балалары арасында киң танылу табачак "Биктырыш" әкият-поэмасын, "Печән чапканда" поэмасын, "Беренчеләр" дип аталган индустриаль эскизларын иҗат итә.

Айдар Хәлим җитәкчелегендә оешма актив сәяси эшчәнлек алып бара. Аның төп юнәлеше – милләт азатлыгы өчен көрәш. Нәкъ менә шушы юнәлештәге эшчәнлек өчен эзәрлекләүләргә дучар ителеп, яшь әдип 1971 нче елны туган җире Башкортстанга кайтып китәргә мәҗбүр була. Туган якларында да ул әдәби эшчәнлеген дәвам итә. 1990 нчы елның салкын октябрь аенда ул, татар халкының хокукларын яклап, Уфа шәһәренең үзәк Совет мәйданында татар тарихында беренче тапкыр сәяси ачлык игълан итә һәм Башкортстан татарлары өчен Туймазы, Уфа татар театрлары оештыруга, яшьләр өчен "Тулпар" журналын, "Өмет" газетасын, Башкортстан китап нәшриятында татар китапларын чыгаруны юлга салуга ирешә.

1991 нче елда Айдар Хәлим Язучылар берлеге һәм Чаллы шәһәр советы тарафыннан яңа оештырылган "Аргамак" журналына баш мөхәррир итеп чакырыла. 1991 – 1995 нче еллар аралыгында ул татар һәм рус телләрендә чыккан бу басманың баш мөхәррире булып эшли һәм аны 90 нчы елларның мәдәни дөньясында иң кызыклы журналларның берсе итеп гамәлгә куюга ирешә.

Айдар Хәлим татар шигърияте, татар прозасы, татар публицистикасы һәм татар әдәби-эссеистик тәнкыйте өлкәләрендә зур активлык белән эшли. 1967 – 2007 нче еллар аралыгында язылган иҗади сурәтләмнәр, әдәби бәхәсләр, әңгәмәләр, ачык хатлар

һәм чыгышларны үз эченә алган икетомлыгы (“Йөрәгебез белән мөстәкыйль”, “Сез беләмсез кая барганны?”) XX гасырның икенче яртысы – XXI гасырның башындагы татар әдәби этик-эстетик фикеренең куәтле мисалы булып тора. 2003 нче елда әдип Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты булуга ирешә. Хәзерге вакытта әдип Татарстанның Яр Чаллы каласында яшәп иҗат итә. Әйтергә кирәк, иҗатының үзенчәлекләре, идея-эстетик кыйммәте, бүгенге әдәбиятта тоткан урыны А.Хәлимнең үзе тарафыннан да тикшерелә. Мәсәлән, балалар шигъриятендә “Орчыкмалай Биктырыш” поэмасының ролен өйрәнгән хезмәте шундыйлардан санала ала [8]. Әдипнең “Кыярга төшкән малайлар”,“Зөлфия дөньяга чыга”, “Казанбаш”, “Өч аяклы ат” чәчмә һәм тезмә әсәрләрдә дә бала образлары мөһим роль башкара. “Тал баласы Талхаветдин” хикәяләр җыелмасы исә үсмерлек чорына кереп баручы балаларны изгелек һәм яхшылык, милли хәтер, җан сафлыгы кебек төшенчәләр белән кызыклы, шул ук вакытта уйланырга этәрә торган формада таныштыра. Татар җанын, татар рухын тоеп яши һәм эшли торган балалар тәрбиләүче мондый әсәрләрне фәнни өйрәнү – бүгенге чорда актуаль проблема булып тора.

Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе. А.Хәлим иҗаты әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан игътибарсыз калмый, аның тормыш юлы һәм иҗаты олпат галимнәр, язучылар тарафыннан өйрәнелә. Мәсәлән, аның иҗатына югары бәя бирүчеләрдән, “милләт каһарманы” дәрәҗәсенә күтәрүчеләрдән Ф.Бәйрәмова, М.Әхмәтҗановны атарга була [11; б. 5]. Әдип иҗаты шулай ук Р.Рахмани [14] һәм Р.Сверигин [17] кебек әдәбият галимнәре тарафыннан төрле аспектларда өйрәнелә.

Фәнни эшнең максаты – Айдар Хәлимнең “Тал баласы Талхаветдин” әсәрен әхлакый һәм фәлсәфи аспектларда анализлау.

Максатка ярашлы рәвештә, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1) А.Хәлимнең балалар әдәбиятында тоткан урынын билгеләү;

2) “Тал баласы Талхаветдин” әсәрендә әхлакый проблемаларның бирелеше һәм чишелешен күрсәтү;

3) Тал баласы Талхаветдин” әсәрендә фәлсәфи проблемалар бирелешен ачыклау.

Тикшеренү объекты итеп А.Хәлимнең “Тал баласы Талхаветдин” әсәре алынды.

Тикшеренү предметы – әсәрдә күтәрелгән әхлакый һәм фәлсәфи проблемалар.

Кулланылган тикшерү методлары: тасвирлама, психологик, чагыштырма.

Эшебезнең гамәли әһәмияте анда тәкъдим ителгән материалның филология факультеты студентлары тарафыннан семинар дәресләргә, конференцияләрдә чыгыш ясарга хәзерләнгәндә кулланылу мөмкинлеге белән билгеләнә.

I бүлек Айдар Хәлим һәм балалар әдәбияты

Балалар әдәбияты – гомуми әдәбиятның кызыклы да, катлаулы да бер өлеше булып тора. Нигездә игътибар олылар әдәбиятына бирелгән әлеге заманда балалар язучыларыннан олы талант, саф күңеллелек, фидакарь хезмәткә сәләтлелек таләп итә. Татар балалар әдәбиятын хәзерге вакытта үсештә, дип атарга була. Шәүкәт Галиев традицияләренең дә дәвамчысы Роберт Миңнуллин, Фәнис Яруллин, Ленар Шәех кебек шагыйрьләр, Галимҗан Гыйльманов, Нәкыйп Каштанов һ.б. проза осталары хисабына байый, үсә. Әмма Айдар Хәлимнең балалар өчен ижаты бөтенләй башка калыпта, башка тел белән, башка идея-тематикаларны колачлап язылган. Мөгаен, әдипнең әлеге өлкәгә карата үз концепциясе барлыгы турында фикер йөртеп буладыр, һәм ул түбәндәге җөмләләрдә чагылыш таба: “Максат бер: татар милләтен бар иткән сыйфатлар ачылган барлык әдәбиятыбызны сөреп чыгып, бары тик иң кирәге, бары тик иманлысын, мәгънәлесен сайлап алырга, татар сәгадәте, татар әхлагы, татар тотрыклылыгын таркатучы, ашаучы, имгәтүче барча чүп-чар әдәбияттан арындырып, яңа тормышка, яңа чорларга куркусыз алып баручы милләт тәрбияли торган әсбап-дәреслекләр төзү. Ялган, ясалма, милли рухны черетүче “пирамидалар” җимерелергә тиеш!” [8; б. 266]. Икенче төрле әйткәндә, әдип балалар әдәбиятын, шул исәптән, дәреслекләрне дә милли рух тәрбиясенә хилафлык

китергән, рус, Көнбатыш Европа әдәбиятына таянып язылган, бары көлке, сүз уйнатуга гына кайтарып калдырылган, һәм шуның белән бер бала тәрбиясенә генә түгел, гомумән, милләт үсешенә дә зыян китергән әсәрләрдән арындырырга чакыра. Алмашка әдәпле, инсафлы, югары әхлак сыйфатларын пропагандалаган, Габдулла Тукай традицияләрен дәвам иткән әсәрләр килергә тиеш, дип яза Айдар Хәлим. Аның үзенең әсәрләре – нәкъ әнә шундыйлар. Алар сан ягыннан күп түгел, әмма бу әсәрләр – татар рухы белән өртелгән булулары, иманлы буын тәрбияләүдә гаҗәеп зур потенциалы белән аерылып торалар. Балалар аны, кагыйдә буларак, Биктырыш исемле малай турында язучы буларак беләләр.Әдип үзе героеның барлыкка килүен сугыштан соңгы авыр тормыш, үзенең тәрҗемәи хәле белән бәйләп аңлата. “Безнең буынның балачагы сугыштан соңгы елларга туры килде. Кырыгынчы еллар ахыры иде. Сугыштан хәлсезләнеп һәм хәерчеләнеп калган авылыбызда иркә балалар юк иде. Андый бер генә малайны да хәтерләмим мин”,– дип яза шагыйрь [6; б. 1]. Ачлык-ялангачлыкның бар михнәтен татып үссә дә, бу буын күңел төшенкелегенә бирелми торган көчле шәхесләрдән тора. Автор балаларда Биктырыш исемле каһарман үрнәгендә тырышлыкка, шәфкатьлелеккә, илгә тугрылыкка гына өйрәтеп калмый, ә милли гореф-гадәтләргә ихтирамлы караш та тәрбияли.

Аның шигъриятендә сурәтләнгән балалар – ләззәт-бәхет, уен-көлке эчендә рәхәт көн күрүчеләр түгел, ә олылар тормышының авыр, аянычлы якларын үз җилкәләрендә бөтен тулылыгы белән татучылар. “Казлар көтүче малай турында баллада” (1968) – шуның ачык мисалы:

Бар җиһазы – киндер күлмәк, киндер ыштан,
Чебиләгән аяклары – нәкъ күн итек.
Кочаклаган да үз җирен иң җиткәнче,
Сүнгән сабый, – арыгандыр казлар көтеп [9; б. 70].

Айдар Хәлимнең кайбер шигырьләрендә төп игътибар баланың рухи үсешенә, күңел байлыгына бирелә. “Зөлфия дөньяга чыга” шигыренә игътибар итик. Әсәрдә сүз кызның кечкенә, әмма никадәр төгәл, образлы фикер йөртү нәтиҗәсендә ясалган ачышлары турында бәян ителә.Шигырь тулаем кызның күзәтүләреннән тора: аныңча, “үләннәр бәүбәү итәләр”, әмма агачлар йоклый алмый, чөнки ятсалар, аларга торуы бик авыр булачак; тәрәзләрдә ут балкыган кичке өйләргә карап, кыз: “көндез өйләр бар иде, күзләре юк иде, хәзер өйләрнең күзе бар”, дигән фикерне әйтә һ.б. Галәм белән кеше бәйләнешен сизгер тою, табигатьне җанлы итеп күзаллау – А.Хәлим каһарманының үтә матур сыйфаты. Лирик герой аны олыгайган көннәрендә дә сабый күңелле итеп күрергә тели.

Тулаем алганда, А.Хәлимне балачак дөньясына үтә җитди каравы, баланың рухын юк-бар көлке белән алдамавы, бозмавы аерып тора. Р.Сверигин игътибар иткәнчә, “А.Хәлимнең алдагы зур ачышлары геройларның балачакларыннан, тормышның олы, каршылыклы дәрьяларына кучеп барган мәлләрен сурәтләү җирлегендә башкарылыр төсле. Бәлки, балачакта күңелләренә иман нурлары сеңгән нәниләребезнең өметләре олылар дөньясында яңадан-яңа күркәм яклары белән ачылыр дигән фаразыбыз авторның соңгы әсәрләрендә расланып килә. Аның аксакаллары да еш кына сүзнең бик яхшы мәгънәсендәге сакаллы сабыйлар булып чыга, ягъни геройларның күбесе, олыгайгач та, сабыйлыкның кайбер матур сыйфатларын югалтып бетермиләр. Гүя автор өчен кеше гомере – җанда гомер буе дәвам иткән балачак” [17].

Югарыда язылганнарга нәтиҗә ясыйк: иҗаты гражданлык, милли үзаң белән сугарылган А.Хәлим балалар әдәбиятында да сизелерлек эз калдыра. Таланты аңа төрле жанрларга мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә, әдип шул мөмкинлекне иманлы буын тәрбиясе өчен файдалана. Ул экият-поэмалар, балладалар, шигырьләр иҗат итә. Аларның стиле, теле аерылып тора, әмма берләштерүче үзәк тә бар: Биктырыш та, казлар көтеп арган малай да, өч яшьлек Зөлфия дә – физик һәм рухи яктан сәламәт булып үсеп килүче буын вәкилләре. Аларны эш сөючәнлек, дуслыкның кадерен белү, милли рух кебек сыйфатлар берләштерә. Эш дәвамында шагыйрьнең бер генә әсәрендә дә икеле алучы,

ялкауланучы, куштанланучы, хәтта телевизор караучы бала образы очрамады. Аның әсәрләрендәге балалар олыларга хас проблемаларны хәл итәләр, олылар тормышы белән яшиләр. Әдипнең тал образына мөрәҗәгать итеп язган, асылда татар язмышы, татар тарихы турында бәян иткән "Тал баласы Талхаветдин" әсәре дә аерым игътибарга лаек.

II бүлек Айдар Хәлимнең "Тал баласы Талхаветдин"
әсәрендә әхлакый катлам

Әхлак – бер-берсенә бәйле булган, шулай да җитди рәвештә аерылып торган ике аспектны – бер яктан, шәхесне характерлаучы сыйфатларны (шәфкатьлелек, җаваплылык, иманлылык, мәрхәмәтлелек һ.б.лар); икенче яктан – әхлакый нормалар, кануннар, таләпләр җыелмасын ("үтермә", "урлама", "алдашма") алган катлаулы категория. Татар милли педагогикасында әхлак төшенчәсе дигәндә, "кешеләрнең бер-берсенә һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләр калыбы, кысасы һәм мәсләкләре тупланмасы"н күз уңында тоталар [10; б. 116]. Әлеге фәнни эшебез кысаларында әхлак тәрбиясенең никадәр әһәмиятле, халык, милләт һәм гомумән, Җир шары яшәешен тәэмин итүче төп шарт булуына тукталып тормыйча, әхлак сыйфатларын формалаштыру проблемасының "Тал баласы Талхаветдин" әсәрендә гәүдәләндерелү үзенчәлекләрен өйрәнүгә йөз тотачакбыз.

"Тал баласы Талхаветдин" – унтугыз хикәядән гыйбарәт уртача күләмле чәчмә әсәр. Һәрбер бүлек кысаларында диярлек нинди дә булса бер әхлак сыйфаты ачыла бара яисә әдипнең милләт язмышы турындагы уйланулары бирелә:

– "Болыттан туган тал баласы" хикәясе кешелекнең барлыкка килүен тасвирлый;

– "Таллар шатлыгы" – символик һәм аллегорик образлар аша башка милләтләр белән беррәттән татар милләтенең формалашуын күрсәтә;

– "Төн һәм Көн" бүлегендә исә, табигать күренешләренең асылын аңларга омтылу, камил җиһанны ятатуы өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булу сыйфатлары макталалар;

– "Һавалар нигә зәңгәр?" хикәясендә әдип яңадан татар тарихын символлар аша бәян итүгә күчә, Ак Колак кавеме тискәре образы аша татарларның бөтен дөнья буйлап таралышының, моңлы халык булып җитешүенең сәбәпләрен аңлата, шулай ук татар халкы кичергән авырлыкларның аларга аерым хәтер бүләк итеп, аларны беркайда да адашмас һәм беркайчан да бер-берсен ташламас нәселгә әверелдергәнлеген күрсәтә.

– "Арбадагы сәяхәт" нәни хикәясендә тырышлык, хезмәт сөючәнлек, гаделлек белән идарә итә белү милли сыйфатлар итеп сурәтләнә;

– "Кем акча югалтты?" бүлеге кысаларында Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булу, ул куйкан кануннар буенча яшәүнең әһәмияте турында сөйләнә;

– "Йөзү остасы" бүлегендә әдип тырышлык һәм тирән акыл белән теләсә нинди авырлыкны җиңеп була, дигән фикер үткәрә;

– "Диңгез ярында сөйләшү" бүлеге авырлыкларга бирешми торган, иманга тугрылыклы шәхес тәрбияләү турындагы идеяне үз эченә ала;

– "Уенчыклар кибетендә" әхлаксыз һәм матди байлыкка бирелгән балалар белән иң югары кыйммәтне Ватанны ярату, аңа хезмәт итүдә күргән Талхаветдин капма-каршы куелалар;

– "Беренче намаз" иман нурын яңарту идеясе белән сугарылган;

– "Кискән саен үсә торган тал-металл" татар халкының үлемсез һәм иманлы милләт булуын ассызыклап үтә;

– "Үзегеңне сакла, балам!" үзеңә тугры калу, сабырлык сыйфатларына мәдхия укый;

– "Кайсы тәмлерәк?" бүлеге кысаларында сүз һәр милләтнең үз гореф-гадәтләренә тугрылык саклаганда гына физик һәм рухи сәламәт булып кала алуы турында аллегорик образлар аша күрсәтелә;

– "Күрше хакы" бүлегендә Айдар Хәлим үзара ярдәмләшеп яшәүнең кыйммәтен аңлатуга йөз тота һ.б.лар.

Хикәяләрнең исемнәренә һәм темаларына күзәтү ясау гына да аларның эчтәлекләре катламлы булуын күрсәтәләр. Мисал рәвешендә "Кайсы тәмлерәк?" бүлегенә игътибар

юнәлтеп үтик. Беренче карашка хикәядә һәр балалы гаиләдә була торган типик ситуация тасвирланган: тал баласы бәрәңге ашаудан баш тарта һәм бары тик хәлвә генә ашап торырга әзер булуын белдерә. Ата-ана, оста педагоглар буларак, Талхаветдинне сукмыйачуланмыйлар, ә үз иркенә куялар. Әмма икенче көнне үк, көн буе хәлвә ашап торганнан соң, аның тамак төбе көя, саруы кайный башлый. Шул рәвешле, Талхаветдин ата-ана сүзеннән чыкмаска, ашаган ризыктан канәгатьсезлек белдермәскә тәмле дип тоелган ризыкларның һәрвакытта да файдалы булмавы турында мәгълүмат ала. Әмма хикәянең, безнең фикеребезчә, эчке катламы да бар.

Әсәрнең гомуми идеясе хикәянең эчтәлеген бала капризына кайтарылып кына калмавына ишарә итә. Уйлавыбызча, Айдар Хәлим гореф-гадәтләргә һәм яшәү рәвешенә хыянәт итмәскә чакыра. Әйтик, татар яшәешен рус кануннары буенча кору авылларыбызда эчкечелек таралуына китерде, хәзерге вакытта җәмгыятебезнең Көнбатыш Европа яшәү тибына юнәлеш алуы, коллектив, күмәк яшәү рәвешенә алмашка базар мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар җәмгыяте формашуына, олыларны олы, кечеләрне кече итмәүче буын үсеп килүенә китерде. Бу да, шәхсән, безнең уйлавыбызча, үзебезнең “бәрәңгебез”дән баш тартып, күршеләрнең “хәлвәсе”н ашап сары кайнау күренешедер ул. Мондый күренешкә каршы рәвештә Айдар Хәлим әхлакый кануннарны һәм милли яшәү рәвешенә кире кайту идеясен тәкъдим итә. Аларның иманга һәм изгелеккә нигезләнгән булуы “Күрше хакы” бүлегендә дә дәлилләнә.

Әмма Талхәветдин, кайбер очракларда гади балаларга охшап калып, бәрәңге ашаудан баш тартса да, күпчелек очракларда яше өчен җитди гамәлләр кыла. “Авыл бетмәячәк!...” бүлеге хәзерге вакытта гаять актуаль проблемага багышланган – татар авылы язмышы. Сер түгел, XX йөз ахырыннан башлап, Татарстанда авыл, авыл хуҗалыгы һәм яшьләрнең авылдан китүе кебек проблемалар көн кадагына килеп бастылар. Соңгы берничә елда әлеге проблемаларны хәл итү юнәлешендә кайбер гамәлләр кылынса да, авыллар һаман да бетү һәм таркалу ягында. Ә тарихка мөрәҗәгать итү шуны күрсәтә: илебезнең иң күренекле шәхесләре авылдан чыккан; тарихыбызның иң авыр чорларында, шул исәптән Бөек Ватан сугышы елларында, илебез авылга таянып көч һәм дәрман алган; авыл кешедә тырышлык, үҗәтлек, сабырлык һәм мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар, хисләр тәрбияли. Әгәр җәмгыятебез авылны ихтирам итәргә өйрәнсә, аңа яңадан күтәрелергә ярдәм иткән очракта гына халкыбызның киләчәге турындагы якты уй-хыялларга бирелергә була. Талхаветдин үз өстенә әнә шундый изге миссияне ала. Ул гаризалар язып кына калмый, ә бу эшкә олыларча җитдилек белән якын килә. Нигезе Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы белән, дога укып салынган шушы авыл – Үрнәк авылы! – хикәядәге талларга гына түгел, ә кешеләргә дә өлге, үрнәк булып тора.

Рус авылы турында язган К. Партэ, әсәрләрдә сурәтләнгән авылның башка авыллар белән уртак якларын күрсәтеп, болай язды: “җирле кайбер вариацияләр белән һәр авылның да даими атрибутлары була: торак йортлар (төньякта һәм Себердә агач йортлар, үзәк һәм көньяк төбәкләрдә мазанкалар) һәм йорт яны төзелмәләре (амбар, сарайлар), бакчалар, мунчалар, инешләр, коелар, чиркәүләр һәм зират. Авыл прозасында авылның башка дөньядан аерымлыгы, аның дөнья белән юл, сукмак белән бәйләнгән булуы күрсәтелә” [4; б. 23]. Талхаветдин нигез салган авылның нигезен мәчет һәм мәктәп тәшкил итә, чөнки мәчетсез һәм мәктәпсез авыл кешелекне иманга, прогресска илтә алмаячак.

Әсәр тукымасына кереп урнашкан мәкальләргә игътибар юнәлтсәк, аларда автор фикере шактый кыска һәм тәэсирле булуы күренә. Менә “Арбадагы сәяхәт” бүлеге кысаларында Талхәветдин ат җигәргә тырыша, ләкин, арба алга китсен өчен, аңа тәгәрмәчләр ясарга һәм күчәрләрне майларга туры килә. Шушы бүлектә Айдар Хәлим ак сакаллы тал карты авызыннан “Халыкта “Арба булганчы, ат бул!” дигән сүз бар. ... Бу аның “Батыр бул, идарә итә бел” дигән сүзе иде” [7; б. 10] дигән фикерләрне әйттерә. Укучы өчен бу беркадәр көтелмәгәнрәк нәтиҗә. Ул “хезмәт төбе хөрмәт” яки “кешене эше бизи” кебек

мәкальләрне укырга әзер, әмма идарә итү турындагы мәкальнең әдәби әсәр текстына кертелүе аны тагын да тирәнрәк уйларга этәрә. "Идарә итү әмерләр бирү генә түгел, тырышып эшләү дә әле ул", дигән нәтиҗәгә килә. Чынлап та, әдип хаклы: тәгәрмәчләре куелган, майланган җитәкченең генә аты кузгалырга, җәмгыятькә файда китерергә сәләтле. Талхаветдин образында, безнең фикеребезчә, Айдар Хәлим әнә шундый булдыклы, халыкны авыр хәленнән, милләтне юкка чыгу куркынычы, инкыйраздан коткаручы идарәчене әзерли-үстерә. Һәр хикәядә ачылып барган Талхаветдинга хас әхлакый сыйфатлар: намус, юмартлык, ихтыяр көче, гайрәт һәм батырлык, сабырлык, тырышлык, мәрхәмәтлелек, татулык, бердәмлек, горурлык, изгелек, аны символ дәрәҗәсенә күтәреп – милләтнең киләчәге дигән мәгънәви эчтәлекне сала.

Язылганнарга нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: әсәрдә әхлак кануннарының трансляторлары, ягъни тапшыручылары буларак ислам дине кануннары һәм халык акылы – мәкальләр бирелә, еш кына алар бер-берсе белән үрелеп тә биреләләр. Ислам кануннары нигездә әхлакый нормалар, кануннар, таләпләр җыелмасы рәвешендә аңлашылса, мәкальләр шәхесне характерлаучы сыйфатларга тәгъбир итәләр. Хикәяләргә күзәтү шуны күрсәтә: туган илгә, туган милләткә, иманга береккәнлек – автор тарафыннан олыланган иң күркәм сыйфатлар. Тарихын оныткан милләтләр милләт булудан туктап, халык төркеменә әйләнәләр. Хезмәт сөючәнлек һәм тырышлык кебек сыйфатлар да автор карашында иң югары әхлакый категорияләрдән санала. Әмма ул гадел, камил хөкемдар идеясе белән дә тыгыз үрелеп килә.

III бүлек Айдар Хәлимнең "Тал баласы Талхаветдин" әсәрендә фәлсәфи катлам

Фәлсәфә – фән, дин, сәнгатьтән аермалы яклары булган үзенчәлекле бер өлкә ул. Аның аермалы якларын түбәндәгеләр тәшкил итә:

1) фәлсәфә – фикерләү, уйлау, дигән сүз. Ул һич тә танып белү, тою, кушу, инану, гамәл кылу түгел, бары тик фикер йөртүне күздә тота.

2) фәлсәфә – бер генә кешенең уй-фикерен җиткерүне түгел, ә кешеләрнең күмәк рәвештә уйлауларын таләп итә. Мәсәлән, фән – күмәк танып белүне, сәнгать – күмәк рәвештә хис-тойгыга бирелүне, дин – күмәк рәвештә инануны, сәясәт-хокук – күмәк рәвештә кушу, кушканнан тайпылмауны күздә тоткан кебек, фәлсәфә фикер йөртүгә шундый караштa тора.

3) фәлсәфәнең ахыр нәтиҗәсе булып матурлык яисә ниндидер матди кыйммәт түгел, ә башка бик күп кешеләр өчен дә әһәмиятле булган фикер тора [1; б. 6].

Фәлсәфәнең үсеш дәверендә аның төрле юнәлешләре формалаша. А.Хәлим әсәрендә дини фәлсәфә, яшәеш турындагы фәлсәфә, милли фәлсәфә, акмеология – кыйммәтләр турындагы фәлсәфә кебек катламнар урын ала.

Мәгълүм булганча, Айдар Хәлим барыннан да элек милләт язмышы өчен борчылучы әдип буларак билгеле. Әдип милләт фәлсәфәсенә кагылышлы уйларын дини фәлсәфә идеяләре белән үреп бирә. Дин дигәндә, "табигатьтән өстен торып, Җиһандагы бөтен җанлы һәм җансыз затлар, күренешләр, вакыйгалар, шул исәптән кешенең дә язмышы, һәрбер адымы, фикере-уйлары белән идарә итә торган көчләрнең, мәрхәмәтле яки явыз затларның булуына ышану, аларга табыну, шуларга багышлап, дога кылу, йолалар уздыру, кешенең үзен һәрвакыт шул илаһи көчләрнең колы дип сизүен күздә тотсалар да [5; б. 16], хикәядә сүз, әлбәттә, мөселман дине – Ислам турында бара.

Беренче бик кыска гына хикәя "Болыттан туган тал баласы" дип исемләнә. Әсәр сөрешеннән укучы аны татарның килеп чыгышы турындагы символик хикәя, дип аңлый. Әти-әнисен таба алмау кайгысыннан үксеп-үксеп елаган болытның күз яшьләре тамган җирдә беренче тал – нәсел башы Талхаветдин үсеп чыга. Әдипнең ишарәсе татар тарихын, татар рухын тирәннән белү-тоюны таләп итә. Күз яшьләренә бәйле рәвештә ялау татарның аянычлы тарих сәхифәләренә ишарәдер, дип фараз кылырга мөмкин. Шул ук вакытта әсәрнең буеннан буена татарның бәхеткә лаек олы милләт булу турындагы фикер үткәрелә. Барыннан да элек татар язмышы Ислам дине белән тыгыз

бәйлелектә карала. Мөселман дине милләтебезнең әхлак сакчысы буларак бирелә. Тал баласы Талхаветдиннең гамәлләре мөселман кодексы белән билгеләнә. Барыннан да элек мөселманнарга фарыз гамәлләр кылуны искә алырга кирәк. Әсәрдә сүз нигездә һәрбер мөселманга кылырга тиешле, ягъни фарыз саналган эш һәм гамәлләргә – Аллаһының берлеген тану, намаз уку турында бара. Талхаветдиннәрнең гаиләсендә Аллаһының исеме еш телгә алына: менә Тал-Ана Талхаветдингә Коръән-Кәрим турында сөйли: "Аллаһы Тәгалә кушканча яшәү тәртибен, ул тәртипне аңлаткан кануннар китабын "Коръән-Кәрим" дип атыйлар. Бер Аллаһы Тәгаләгә, аның изге китабы Коръәнгә табынып яшәүне "дин-иман" диләр. Шушы дин-иман нигезендә яшәргә өйрәтүчеләребез исә пәйгамбәрләр була. Безнең пәйгамбәребез – Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһиссәлам шәрифләре. Изге китабыбыз аңа Аллаһы Тәгаләдән Җәбраил фәрештә аша яшерен аваз белән күктән иңдерелгән" [7; б. 12].

Әмма әдип геройлары авызыннан вәгазь укып кына калмый, һәр гамәлнең асыл мәгънәсен дә аңлата. Әйтик, "Кем акча югалтты?" бүлегендә намаз укуның фараз гамәле турында гына бәян ителми, әлеге гамәлнең мәгънәсе дә аңлатыла: "намаз – безгә чиксез байлыклар – ут, су һәм тере булмаган табигатьне бүләк иткән өчен Аллаһы Тәгаләгә китергән рәхмәтебез", – дип аңлата Тал-Ана Тәлхаветдингә.

Әсәрдә ислам дине – әхлак сакчысы буларак тәкъдим ителә. Нәкъ менә дин милләтнең рухи һәм физик сәламәтлеген саклап калучы, дигән фикердә тора автор. Соңгы – "Шифаханәдә" дигән бүлектә, әнисе беләгән авырттыру сәбәпле, Талхәветдин аның белән табиплар янына юнәлә һәм авыручыларның гаять күп санлы булуына таң кала. Ана-Тал аңа авыруларның сәбәбен имансызлык белән аңлата. Иманы булмаган кеше ирексездән авырый башлый. Әдип китергән мәгълүматлар да кызык: җир асты байлыкларыннан үзләре генә файдаланып яшәүче кайбер мөселман илләрендә – Төрекмәнстан, Малайзия, Согуд Гарәбстаны, Катар һ.б.лар – мең кеше исәбеннән чыгып караганда, чирлеләр чагыштырмача аз санда. "Аллаһы Тәгалә иманына килмәгән дәүләтләр ел саен арта барган шифаханәләр саны белән мактансалар, Согуд Гарәбстаны кебек мөселман илләре шифаханәсез, бары гыйбадәттә савыгулары белән үрнәк күрсәтәләр", – ди әнисе тал малаена [7; б. 46].

Айдар Хәлимнең кеше һәм милләт тормышында динне югары бәяләве аның шәхси позициясе белн генә аңлатылмый, әдипнең иманлы, динле, саф күңелле шәхес булуы шик уятмый, әмма ул дин фанатигы буларак түгел, ә дөньяның ачысын да, төчесен дә мул татыган шәхес буларак фикер йөртә. Фикеребезне икенче бер әдип язмышы һәм уйлары белән дәлилләп китәсебез килә. Мәгълүм булганча, классик татар әдибе, гыйбрәтле язмыш иясе Аяз Гыйләҗев лагерь юлларын татыган, анда зыялы гаепсез хөкем ителгән зыялылар белән күп аралашкан шәхес була. Аның атаклы әсәрләре "Ягез, бер дога!" һәм "Балта кем кулында?" әсәрләрендә халык, милләт яшәешендә диннең урыны турында да фикер әйтелә. Бер генә мисал китерик: "Дин – милләтнең таянычы. Рус мәмләкәтенең уртасында торып калган татарларны милләт буларак, тел-ил берлеге генә түгел, ислам дине дә яшәткән, аларны оештырып тоткан, милли рухны саклаган. Иван Грозный Казанны яулап алганна соң, күпме кимлекләр, җәбер-җәфалар күрсәләр дә, татарлар милли йөзләрен югалтмаган, чөнки дин яшәгән, дин саклаган. Дин халыклар күңеленә яктылык иңдергән, белем, гыйлем китергән" [2; б. 147].

Дингә бәйле рәвештә әдип халкыбызның аянычлы тарих битләренә дә кагылып үтә. Иман нуры белән рухланган Тәлхаветдин әнисеннән фарыз гамәлне үтәмәү – намазга басмавының сәбәбен сорый. Тал-Ана аңа динсез заманда үсүе, дин тоткан өчен эштән, укудан куыла торган заманда яшәве, ә хәзер рухи әзерлек җитмәве, Коръән аятьләре һәм сүрәләрен яттан белергә кирәклеге турында бәян итә. Талхаветдин әнисен кызганып куйса, укучы шушы сүзләр артында олы бер фаҗига ятуын аңлый. Динне тыйган советлар чорында имансыз, димәк, әхлаксыз бер буын үсеп җитү фаҗигасе, шул елларның кайтавазы һаман да ишетелеп торуын хәзерлекле укучы аңлый, әлбәттә.

Әсәрнең фәлсәфи катламының берсен яшәеш кануннары турындагы уйланулар тәшкил итә. Болар “Диңгез ярында сөйләшү” бүлегендә ачык чагылыш табалар. Хикәядә аллегорик образлар аша “кыйналып җиңәргә өйрәнү” идеясе үткәрелә. Хикәя түбәндәге вакыйганы бәян итә: Талхаветдин диңгез дулкыннары тарафыннан кыйналган Аю-Дагны кызганып елый башлый, әмма текә кыя аңа “тормышта язылмаган кануннар бар. Аларның берсе – кыйналып җиңәргә өйрәнү. Син дә кыйналып җиңәргә өйрән, и мәрхәмәтле тал баласы! Тыңла мине! Үзеңне үстергән тугай-далаңа кайт. Даланаң яңгырлары, өйермәләре белән каккалап-суккалап үстерсен сине. Җил-давыллар, тирбәтеп, ботакларыңны сындыра алмаслык итеп ныгытсын” [7; б. 17].

Әлеге хикәянең мәгънәләре тирән, автор фикере төрле катламнарда аңлашылырга мөмкин. Беренчедән, баланы чыныктыру, артык иркәләмәү фикере үткәрелә. Шул вакытта гына ул уенчык, тәмле әйбер һәм башка ләззәтләрнең кадерен аңлый башлый, тормыштагы авырлыкларга беркадәр әзерлеклелек тоя. Икенчедән, кыйналып ныгыган образ укучы күңелендә ирексездән татар милләте белән янәшә куела башлый. 1552 нче елдан хәзергәчә күпме михнәт күргән халыкның сынмавы, сынатмавы горурлык хисе уята. Өченчедән исә, кыя образы – Айдар Хәлим үзе, ә тал баласы – аның яшь укучысы буларак та аңлашылырга мөмкин. Айдар Хәлим – бөтен гомерен милләтнең иманлы киләчәгенә багышлаган олпат зат, әмма нәкъ менә туры сүзе, хөр фикере өчен аңа яшәү урынын алыштырырга, ач торырга, башкалар, аннан күпкә талантсызлар премияләр алганда, читкә тибәрелергә мәҗбүр була. Шулай да ул бирешми, эшчәнлеген дә, иҗатын да дәвам итә, роман, повестьләрен бастырырга көч һәм дәрман таба. Укучысына да ул җил искән якка башын боручы түгел, ә авыр шартларда да иманына тугрылыклы шәхес булып калуын тели.

Яшәеш кануннары турындагы фәлсәфи уйланулар “Булмаганны чүпли” бүлегендә дә урын ала. Бүлектә “булганны да, булмаганны да чүпли торган” чыпчык һәм Талхаветдин арасындагы сөйләшү турында бәян ителә. Хикәя ахырында автор: “Бер-берсеннән аерылып торсыннар өчен, “булган” белән “булмаган” янәшә яратылган. Кара әле: син менә кара туфракны яратасың. Ә җир катламнарында туфрак кара гына буламы? Юк. Сары, соры, ташлы-комлы, кызыл балчыклы катламнар да булган. Игендә тук орлык кына буламы? Юк, ач орлык та була. Язгы ташу “булган”ны гына агызамы? “Булмаган”ны да агыза. Кешеләрнең “булган”нары гына булмы? “Булмаган”нары да бар. Берсен икенчесеннән аерыр өчен...” [8; б. 40]. Шул рәвешле әдип тормышта начарның да, яхшының да, акның да, караның да яшәргә хокукы булганы турында әйтә. Әгәр мондый бүленеш булмаса, кеше яхшыны начардан, рәхәтне михнәттән аера алмас иде.

Әсәр буеннан буена милли идея белән сугарылган. Авторның фикерләре тарихка, дингә генә түгел, этнографик үзенчәлекләргә дә кагылышлы рәвештә яңгыратыла. “Хурлама бәрәңгене! Ул – безнең милли ризыгыбыз”, – дип кисәтә улын Ана-Тал [2; б. 27].

Хезмәтләренең берсендә А.Хәлим “Без исән калу юлында дин, мәдәният, мәгърифәт, сәнгатьнең роле турында уйланырга тиешбез”, – дип яза [16; б. 384]. Балалар өчен язылган кайбер башка әсәрләрендә кебек үк, Айдар Хәлим “Тал баласы Талхаветдин”дә дә сәнгать, әдәбият темасын читләтеп узмый. Әлбәттә, авторның игътибары сөекле татар улы – Габдулла Тукайга юнәлә. Исебезгә төшерсәк, әдипнең нәни герое Биктырыш турындагы әсәрендә халык иҗатына зур урын бирелгән иде, “Тал баласы Талхаветдин”дә дога юллары белән бер рәттән “И туган тел” шигыреннән өзекләр яңгырый:

-“Анда җир йөзендәге һәр кешегә якын һәм кадерле сүзләр язылган! – диде малай. – Аларны безнең бөек шагыйребез Габдулла бабай Тукай иҗат иткән:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы”, – дип белдерә шатлыгын тал малае Талхаветдин [7; б. 43].

Айдар Хәлимне без кыю публицист, хөр фикерле, хөр рухлы шәхес буларак беләбез. “Тал баласы Талхаветдин”дә дә аның әсәрләрендә урын алган фикерләр, идеяләр бирелә,

әмма алар яшеренгән, символлар, образлар артында торалар. Әсәр – унике яшькә җиткән яисә олырак балаларга атап язылган, автор яшь укучыны үзенең фәлсәфи дөньясына, милли азатлык, хөрлек идеяләре белән сугарылган дөньяга керергә әзерли. Әсәрнең һәрбер бүлеге тирән мәгънә белән сугарылган. Әсәрдән аңлашылганча, тал – ныклы, "кискән саен үсә торган тал-металл, тал-татар" – татар милләте турында. Милли фәлсәфә дини фәлсәфә белән тыгыз бәйлелектә бирелә. Әмма милләт язмышында диннең ролен югары билгеләвендә автор ялгыз түгел, татарның атаклы шәхесләре, шул җөмләдән, Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә дә шул ук фикер әйттерелә. Кыскасы, "Тал баласы Талхаветдин" әсәренең һәрбер бүлеген, анда никадәр гади яисә катлаулы вакыйга тасвирланмасын, дини һәм милли күзлектән караганда гына тирән фәлсәфи катламын күрергә, аңларга мөмкин.

Йомгак

Әдәбиятыбызда тәнкыйтьчеләр тарафыннан да, галимнәр тарафыннан да аз өйрәнелгән өлкәләр, иҗатлары җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелмәгән каләм ияләре бар. Айдар Хәлим – шундыйларның берсе. Дөрес, фикердәшләре-каләмдәшләре аның иҗатына гомуми бәя бирәләр, кыю фикерле һәм сынмас рухлы булуы тәнкыйтьчеләр тарафыннан да ассызыкланып кителә. Әмма әдипнең иҗат лабораториясе тәфсилләп тикшерелмәгән, әсәрләренә төпле анализ әлегәчә ясалмаган. Бигрәк тә әдипнең балалар әдәбияты өлкәсендәге иҗатында ак таплар күплеге күзгә ташлана.

Әлеге фәнни эше кысаларында без "Тал баласы Талхаветдин"нең идея-тематик эчтәлеген әхлакый һәм фәлсәфи яктан өйрәнүне максат итеп куеп, әдипнең хәтта балалар өчен язган әсәрләренең дә күп катламлы, төрле дәрәҗәдә әзерлекле укучыга юнәлгән булуы, хәтта, әйтер идек, интеллектуаль проза дәрәҗәсендә торуын ачыкладык. Беренче карашка, "Тал баласы Талхаветдин" тал баласының, ата-ана, башка таллар һәм гомумән әйләнә-тирәлек белән мөнәсәбәте турында язылган, аның эченә тормышта була торган гадәти ситуацияләр дә кертелгән. Кайсы бала әни пешергән ризыктан баш тартып, тәмле әйбер генә ашарга хыялланмаган? Кибеткә кереп уенчык сорап елаган балалар да шактый. Әмма әдипнең игътибары асылда бик җитди проблемаларга юнәлгән. Җиде яшьлек тал баласының әйләнә-тирә белән танышуын күзәткән укучы алдында татар тарихы, татар характеры, татар язмышы, татар дине – мөселман дине турындагы зур картина пәйда була. Ул нигездә әхлакый һәм фәлсәфи катламнар аша гәүдәләндерелә.

Талхәветдин әхлак кануннарының асылын дини кагыйдәләр аша һәм халкыбызның зирәк акылы булган мәкальләр аша җиткерә бара. Айдар Хәлим өчен иң югары кыйммәтләр булып хезмәт сөючәнлек, тырышлык, белем алуга омтылыш, Ватанга мәхәббәт, ата-ана һәм күрше хакын хаклау кебек сыйфатлар торалар. Әдипнең Биктырышы да шушы сыйфатларга ия булган иде, Талхәветдиндә алар тагын да югарырак катламда тасвирланганнар, герой сыйфатлары буларак кына түгел, ә милли характерның үзэген тәшкил итүче сыйфатлар булып аңлашылалар. Айдар Хәлим шигъриятендә дә, проза жанрында иҗат ителгән әсәрләрендә дә балалар һәм олылар дөньясы кискен рәвештә бүленми. Аның каһарманнары олыларның мәшәкатьле авыр тормышы эчендә яшиләр, фәлсәфи фикер йөртәләр, яшәү-яшәеш турында уйланалар, хәлдән килгәнчә, олыларга ярдәм күрсәтәләр. Бу яктан, аның геройлары, әлбәттә, Шәвәлиләрдән аерылып тора.

Әсәрнең фәлсәфи катламнары берничә. Әхлак кагыйдәләренә кагылышлы фәлсәфә – акмеология дин белән бәйләнештә бирелә. Яшәеш фәлсәфәсе чыпчык, Аю-Даг образлары аркылы бирелә. Әдипнең игътибары милли фәлсәфәгә дә юнәлтелә. Нәкъ менә ул әсәрнең үзэген тәшкил итә һәм татар язмышы темасына төрелеп бирелә. Төрле хикәяләр нигезендә татар милләтенең киләчәге дин үсеше, авылны саклап калу, мәгариф системасының нәтиҗәле эшләве шартларында гына бәхетле булырга мөмкин, чит, ят кануннар буенча яшәү милләтне зәгыйфь һәм авыру итәчәк, дигән идея үткәрелә.

Кыскасы, Айдар Хәлимнең балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге аерым үзенчәлекләргә ия. Ул балаларны олылар белән тиң күреп, алар белән олылар телендә

сөйләшә. Аларда эш сөючәнлек, Ватанга мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләүне төп максат итеп куя. “Тал баласы Талхаветдин” әсәре мәктәп яшендәге балаларга аталып язылып, фәлсәфи тирәнлеге белән олыларны да таң калдырырлык әсәр буларак бәяләнә ала. Әдипнең башка әсәрләре кебек үк, “Тал баласы Талхаветдин” дә фәнни өйрәнүгә лаек. Әмма игътибарны икенче юнәлешкә дә бирәсе килә. Соңгы елларда Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә нигезләнеп язылган яңа дәреслекләр дөнья күрде, әмма аларда Айдар Хәлимнең “Орчык-малай Биктырыш” экият-поэмасы да, “Тал баласы Талхаветдин” хикәяләр җыентыгы да урын алмаган. Шәхсән, безнең уйлавыбызча, ике әсәрдә моңа лаек. Әлбәттә, рус телле балаларга татар рухын аңлавы да, әсәрләрне укуы да катлаулы булыр иде, әмма татар мәктәпләре өчен язылган дәреслекләрдә Айдар Хәлимнең әлеге әсәрләре урын алырга лаек.

## Литература

1. Балашов, Л.Е. Философия: учебник / Л.Е. Балашаов. – Москва: “Дашков и К”, 2012. – 612 с.
2. Гыйләҗев, А. Балта кем кулында?: кереш сүз автор Ф.Ә. Ганиева / А. Гыйляҗев – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 320 б.
3. Даутов, Р.Н. Әдипләребез: биобиблиграфик белешмәлек: 2 томда: 2 том / Р. Н. Даутов, Р. Н. Рахмани. / – Казан: Татар. кит. нәшр, 2009. – Б. 564 – 568.
4. Партэ К. Русская деревенская проза: светлое будущее / К. Партэ. – Томск: Том. ун-та, 2004. – 204 с.
5. Урманче, Ф. Татар мифологиясе: Энциклопедик сүзлек: 3 томда / Ф. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2009. Т.2. – 343 б.
6. Хәлим, А. Биктырыш: балалар өчен поэма / А. Хәлим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 148 б.
7. Хәлим, А. Тал баласы Талхаветдин: балалар өчен нәни хикәяләр /А. Хәлим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 48 б.
8. Хәлим, А. Татар балалар шигърияте һәм “Орчык-малай Биктырыш” (бүгенге балалар шигъриятенә фәлсәфи күзәтү) / А. Хәлим. – Чаллы: ҖЧҖ Диамант, 2010. – 268 б.
9. Хәлим, А. Тилергән сирень: шигырьләр, баллададар / А. Хәлим. – Казан: Рухият, 2003. – 608 б.
10. Шәймәрданов, М.Х. Татар милли педагогикасы: югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку ярдәмлеге / М.Х. Шәймарданова. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.
11. Әхмәтҗанов, М. Милләт каһарманы / М. Әхмәтҗанов // Мирас. – 2000. – № 10. – Б. 54 – 62; №11. – Б. 94 – 98.
12. Бәйрәмова, Ф. Ак һәм кара көрәше / Ф. Бәйрамова // Казан утлары. – 2001. – № 12. – Б. 119 – 128.
13. Галиева, Л. Иңнәрендә милләт вазифасы / Л. Галиева // Көмеш кыңгырау. – 2012. – 7 февр. – Б. 1.
14. Рахмани, Р. Бара шагыйрь төпкә җигелеп / Р. Рахмани // Идел. – 2002. – № 5. – Б. 60 – 65.
15. Хәлим, А. Кем анда? / А. Хәлим // Казан утлары. – 1998. – № 4. – Б. 149 – 154.
16. Хәлим А. Мин нигә драматург булалмадым // А.Хәлим. Пьесалар. – Казан: Идел-Пресс, 2004. – Б. 141 – 401.
17. Сверигин Р. Кыйблага кайту. – URL: http://kazanutlary.ru/?p=22716; мөрәҗәгать итү датасы: 10.05.2017.

## Автор публикации

**Г.М. Галимуллина,** студент, Набережночелнинский государственный педагогический университет, email: galimullina.96@mail.ru

***Abstract***. *In this scientific work, a short essay on the life and work of a well-known Tatar poet, playwright and publicist is produced. The moral-philosophical layer of his work “Son of Willow Talhavetdin” is considered. And also the ideological and thematic content of the story is analyzed*
***Keywords***: *moral and philosophical stratum, idea, national concept, symbol*

## Author of the published work

**G. Galimullina**, student, Naberezhnye Chelny State Pedagogical University, email: galimullina.96@mail.ru

**Дата поступления 12.03.2018**